ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.11.2021 п.г.т.Алексеевское № 408

**«2020 - 2025 елларга Алексеевск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына үзгәреш кертү турында**

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасының 3 нче кушымтасына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 25 сентябрендәге 916 номерлы карарын игътибарга алып,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 30 апрелендәге 156 номерлы карары белән расланган «2020 - 2025 елларга Алексеевск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына 1 нче кушымтага, 35 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Сатып алына торган торак бина (шул исәптән өлешле төзелеш объекты) Татарстан Республикасы территориясендә булырга яки торак йорт төзелеше гамәлгә ашырылырга тиеш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**